**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды пос., Гагарин ур., 7

тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail:Kurk.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**
**31 январь 2024 ел** | **№ 1**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы карарына ярашлы. «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 23.01.2024 № 46 карарларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2024 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370 сум 20 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 15.04.2021 № 10 карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora. tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Коркачык авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф. Салихҗанов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль
районы Коркачык авыл җирлеге башкарма
комитетынын 31.01.2024 №1 карарына

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең 2024 елның 1 февраленнән булачак бәясе

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5542,3 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып бару | 669,31 |
| 4. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Нибары | 8370,2 |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль
районы Коркачык авыл җирлеге башкарма
комитетынын 31.01.2024 №1 карарына

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе
2024 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләу, кием киерту | 301,18 |
| 3. Каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5241,12 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка ташу | 669,31 |
| 5. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Нибары | 8370,2 |